ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.12.2019 Казан шәһәре № 5-121/тэ

«ТГК-16» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә 2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2018 № 5-92/тэ карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2020 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә һәм, 2020 елга җайга салынулы оешманың план буенча кирәкле тулай керемен тәгаенләп, 2020 елга «ТГК-16» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә дәвамлы тарифларга төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының ««ТГК-16» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә 2019-2023 елларга тарифлар билгеләү турында» 19.12.2018 № 5-92/тэ карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

аталышында «ТГК-16» ачык акционерлык җәмгыяте» сүзләрен «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «ТГК-16» ачык акционерлык җәмгыяте (алга таба – «ТГК-16» ААҖ)» сүзләрен «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте (алга таба – «ТГК-16» АҖ) сүзләренә алмаштырырга;

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтада «ТГК-16» ААҖ» сүзләрен «ТГК-16» АҖ» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2018 № 5-92/тэ карарына 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.12.2019 № 5-121/тэ карары редакциясендә)

## «ТГК-16» АҖ тарафыннан җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясен сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә 2019-2023 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынулы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукция ләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| 1. | «ТГК-16» АҖ | | | | | | | |
| 1.1 | Казан шәһәре | | | | | | | |
| | Бер ставкалы тариф, сум/Гкал | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 682,82 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 910,54 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 824,54 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 855,28 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 741,35 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 793,37 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 780,37 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 785,05 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 785,05 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 835,56 | - | - | - | - | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2018 № 5-92/тэ карарына 2 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.12.2019 № 5-121/тэ карары редакциясендә)

## Билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулыннан файдаланып тарифлар формалаштыру өчен 2019-2023 елларга җайга салуның озак сроклы чорына билгеләнә торган озак сроклы җайга салу параметрлары

| т/с | Җайга салынулы оешманың аталышы | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Җылы белән тәэмин итүнең ышанычлылык дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Ягулыкка чыгымнарны үзгәртү динамикасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | мең сум | % | % | Билгеләнгән куәтнең 1 Гкал/сәг өчен җылылык энергиясе чыганакларында технологик хилафлыклар нәтиҗәсендә җылылык энергиясен бирүне туктатып торулар саны | Җылылык энергиясе чыганаклары коллекторларыннан җибәрелә торган җылылык энергиясе берәмлеген җитештерүгә чыгымның чагыштырма чыгымы, кг/Гкал | |
| 1 | «ТГК-16» АҖ | | | | | | | |
| 1.1 | Чыганак – «ТГК-16» АҖ филиалы – Казан ҖЭҮ-3 | 2019 | 352 899,49 | X | X | 0 | X | X |
| | | 2020 | X | 1 | X | 0 | X | X |
| | | 2021 | X | 1 | X | 0 | X | X |
| | | 2022 | X | 1 | X | 0 | X | X |
| | | 2023 | X | 1 | X | 0 | X | X |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге